**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 151** **« 07 » 03 2019 ел**

**ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78нче маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" №131-ФЗ Федераль закон нигезендә, РФ Хакимиятенең 2016 елның 6 сентябрендәге "Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне көйләүче норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында" 887нче Карарына таянып, сөт җитештерүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплау максатында, шулай ук Спас муниципаль районында сыерларның баш санын саклау һәм арттыру буенча чаралар үткәрү максатында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибен расларга (N 1 кушымта).
2. ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирүгә гаризаларны тикшерү комиссиясенең составын расларга (№ 2 кушымта).
3. ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирүгә гаризаларны тикшерү комиссиясе турында положениене расларга (№ 3 кушымта).
4. Субсидияне бирү турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

Кушымта N 1
Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районы
башкарма комитеты карарына
"07" "03" 2019 ел. N 151

**ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибе**

## 1. Субсидия бирүнең гомуми положениеләре

1.1.Түбәндәге тәртип ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү процедурасын (алга таба – субсидия) билгели.

1.2. Субсидия бирү савым сыерларның баш санын һәм терлекчелек продукциясе җитештерүне саклауны тәэмин итү, гражданнарның шәхси ярдәмче хуҗалыкларында савым сыерларның баш санын арттыруны стимуллаштыруны максат итеп куя.

Субсидияләр бушлай бирелә һәм аларны кире кайтарып бирергә кирәкми.

1.3. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчаларын алучылар буларак тиешле тәртиптә тәгаен финанс елына (алдагы финанс елына һәм пландагы чорга) субсидияләр бирүгә бюджет бурычлары лимитлары җиткерелгән җирле үзидарә органы – бюджет акчаларын алучы буларак төп җитәкче (алга таба – башкарма комитет) булып тора.

1.4. Субсидия шушы тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән җирле бюджетның бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чигендә бирелә.

1.5.Субсидияне физик затлар – алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучылар ала (алга таба – Алучылар).

1.6. Субсидияне түбәндәге таләпләргә җавап бирүче гражданнар алырга хокуклы:

- Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә теркәлгән гражданин;

- субсидиягә гариза биргән чакта гражданинның шәхси хуҗалыгында авыл җирлегенең хуҗалык китабында теркәлгән алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер булырга тиеш;

- җир участокларыннан рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып бару өчен бирелгән яки сатып алынган җир участогының булуы.

## 2. Субсидия бирү тәртибе һәм шартлары

2.1. Субсидияне алу өчен гражданин шәхесне раслаучы документ белән бергә,

башкарма комитетка гариза белән түбәндәге документларны тапшырырга тиеш:

- ИНН таныклыгы күчермәсе;

- хуҗалык китабыннан авыл җирлеге башлыгы тарафыннан расланган, гариза биргән көнгә савым сыерларның баш саны күрсәтелгән өземтә;

- субсидияне күчерү өчен счет номеры;

- субсидияне алу өчен мөрәҗәгать иткән айдан алдагы айның беренче көненә салымнарның барлык төрләре һәм үзара салым буенча бурычлар булмауны раслаучы белешмә;

- сатып алынган саву аппаратының бәясен түләүне раслаучы документларның күчермәләре (квитанция, касса яки товар чегы һәм башкалар);

- җайланма (саву аппараты) паспортының күчермәсе;

- булган очракта, сату-сатып алу (китереп бирү) килешүе.

Аппарат агымдагы елда сатып алынырга тиеш, аны җитештерү срогы субсидия бирү турында гариза язган алдагы елының 1 гыйнварыннан иртәрәк булмаска тиеш.

2.2.Башкарма комитет Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бирү турында гаризаларны карау буенча комиссия йөзендә 7 эш көне эчендә шушы Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларның дөреслеген тикшереп, субсидия бирү турында карар чыгара яки сәбәпләрен күрсәтеп, субсидия бирү турында үтенечне кире кага.

Карар протокол рәвешендә эшләнә.

2.3.Субсидия бирү турында гаризаны кире кагу өчен сәбәпләр:

Субсидия алырга дәгъва итүче тапшырган документларның шушы Тәртипнең 2.1 пунктына туры килмәү яки тиешле документларны тапшырмау (тиешле күләмдә тапшырмау);

субсидия алырга дәгъва итүче биргән мәгълүматларның чынбарлыкка туры килмәве.

2.4. Шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр аппарат бәясенең 95% күләмендә, иң күбе 25000 (егерме биш мең) сум бирелә.

Шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия бер тапкыр бирелә.

2.5. Комиссия уңай карар чыгарган очракта, башкарма комитет боерык нигезендә муниципаль берәмлекнең финанс органы субсидиянең шушы төре өчен билгеләгән типтагы формада субсидия бирү турында килешү төзи һәм субсидияне гражданин – субсидияне алучы счетына күчерә.

Субсидияләр бюджет акчаларын алучы буларак, баш распорядитель Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны шушы тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән срокларда тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул иткәннән соң, унынчы эш көненнән соңга калмый күчерелә.

2.6. Килешүне төзергә планлаштырган алдагы айның беренче көненә субсидия алучылар туры килергә тиеш булган таләпләр:

субсидия алучыларның Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар, иминиятләштерү взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар буенча бурычлары булмаска тиеш.

субсидия алучыларның хокукый акт нигезендә субсидия бирергә планлаштырылган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар буенча бирелгәннәрен дә, кайтарып бирү буенча срогы чыккан бурычлары һәм хокукый акт нигезендә субсидия бирергә планлаштырылган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты алдында вакытында түләнмәгән башка бурычлары (бу таләпләр хокукый актта күздә тотылган булса) булмаска тиеш;

субсидия алучылар шушы Тәртип нигезендә субсидия бирү планлаштырылган Спас муниципаль районы бюджетыннан башка муниципаль хокукый актлар нигезендә шушы Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга акча алмаска тиеш.

2.7. Субсидия алганнан соң ике ел дәвамында савым сыерларның баш саны кимемәскә тиеш.

## 3. Субсидия бирү шартларын, максатларын һәм бирү тәртибе үтәлешен контрольдә тоту һәм аларны бозган өчен җаваплылык турында таләпләр

3.1. Субсидия бирү шартлары, максатлары һәм бирү тәртибенең үтәлеше бюджет чараларын алучы буларак өлкән распорядитель – башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органы – Спас муниципаль районы контроль-хисап палатасы (алга таба - КХП) тарафыннан мәҗбүри тикшерелергә тиеш.

3.2. Субсидия алучы аны биргәндә куелган шартларны бозып, алар башкарма комитет һәм КХП үткәргән тикшерүләр вакытында ачыкланган очракта, субсидия кире кайтарып бирелергә тиеш.

3.3.Алынган субсидияләрне, субсидия алу өчен тапшырылган мәгълүматларның һәм документларның дөрес булмавын ачыклау буенча башкарма комитетның тиешле таләбен алганнан соң, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджеты керемenә 30 көн эчендә кайтарып бирергә кирәк.

3.4. Субсидия алучы акчаларны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджеты керемenә ирекле рәвештә кайтарып бирүдән баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә алына.

3.5.Тапшырылган документлардагы мәгълүматларның чынбарлыкка туры килүе, бюджет чараларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалану, коррупциягә каршы законнарның үтәлеше өчен субсидия алучы җавап бирә. Таләпләрне бозучыларга карата гамәлдәге законнарда күздә тотылган җаваплылык чаралары күреләчәк.

Кушымта N 2
Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районы
башкарма комитеты карарына
"07" 03 2019 ел. N 151

**ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия алуга гаризаларны карау буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Осокин В.А. | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе – комиссия рәисе |
| Закирова Р.Р. | Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары – комиссия рәисе урынбасары |
| Колчина В.Н. | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге җитәкчесе – комиссия секретаре |
| Вафин Р.З. | Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең производство-маркетинг бүлеге консультанты (килешү буенча) |
| Савинов Д.С. | Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Устина Л.А. | финанс-бюджет палатасы рәисе |
| | ТР Спас муниципаль районы авыл җирлеге башлыклары (килешү буенча) |

Кушымта N 2
Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районы
башкарма комитеты карарына
"07" 03 2019 ел. N 151

**ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия алуга гаризаларны карау буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Осокин В.А. | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе – комиссия рәисе |
| Закирова Р.Р. | Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары – комиссия рәисе урынбасары |
| Колчина В.Н. | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге җитәкчесе – комиссия секретаре |
| Вафин Р.З. | Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең производство-маркетинг бүлеге консультанты (килешү буенча) |
| Савинов Д.С. | Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Устина Л.А. | финанс-бюджет палатасы рәисе |
| | ТР Спас муниципаль районы авыл җирлеге башлыклары (килешү буенча) |

Кушымта N 3
Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районы
башкарма комитеты карарына
"07" 03 2019 ел. N 151

**ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия алуга гаризаларны карау буенча комиссия турында положение**

## 1. Гомуми положениеләр

1.1. Бу положение белән ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия алу өчен гаризаларны карау буенча комиссия (алга таба – комиссия) эшчәнлегенең тәртибе билгеләнә.

2.1. Комиссия үз эшчәнлеген Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, шулай ук шушы Положениегә нигезләнеп башкара.

3.1. Комиссия составы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе карары белән формалаша һәм раслана.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Комиссиянең төп бурычлары:
а) ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы, алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидия (алга таба – субсидияләр) алуга гаризалар тикшерү үткәрүне оештыру;
б) тиешле формага туры килгән гаризаларны сайлап алу һәм субсидия бирү турында карар кабул итү.

## 3. Конкурс комиссиясенең хокуклары һәм бурычлары

3.1. Комиссиягә үз эшен башкару өчен түбәндәге хокуклар бирелә:
а) субсидия алуга дәгъва итүчеләрдән билгеләнгән тәртиптә Комиссиянең эшчәнлеге өчен кирәк булган мәгълүматны соратып алу;
б) субсидиягә дәгъва итүчеләрне үз утырышларына чакыру һәм тыңлау.

Үз функцияләрен башкару максатында, комиссия гражданнарга утырышны үткәрү урыны, көне һәм вакыты турында хәбәр итәргә тиеш.

## 4. Комиссиянең эшләү тәртибе

4.1. Комиссия утырышлары Спас муниципаль районы башкарма комитетына субсидия алырга теләүчеләрдән гаризалар һәм белешмә-расчетлар алынгач уздырыла.

4.2. Комиссия рәис, рәис урынбасары, Комиссия секретаре һәм Комиссия әгъзаларыннан тора (алга таба – Комиссия әгъзалары).

4.3. Комиссия рәисе түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә;
2) Комиссиянең чираттан тыш утырышын җыю турында карар кабул итә;
3) Комиссия утырышларын үткәрүнең урыны һәм вакытын билгели;
4) Комиссия утырышларында рәислек итә;
5) Комиссиянең утырыш протоколларына һәм карарларына кул куя;
6) үз вәкаләтләре чикләрендә Комиссия кабул иткән карарларның башкарылуын контрольдә тота.

4.4. Комиссия рәисе урынбасары Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын үти.

4.5. Комиссия секретаре түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышын үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр итә, аларны тиешле белешмә-мәгълүмат материалалры белән тәэмин итә;

2) Комиссиягә җибәрелгән документларны һәм материалларны кабул итә, аларның дөрес тутырылуын тикшерә, Комиссия утырышында карау өчен әзерли;

3) Комиссия утырышы протоколын алып бара;

4) Комиссия утырышы протоколын һәм Комиссия карарларын тутыра.

4.6. Комиссиянең башка әгъзалары түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) Комиссия утырышларында һәм Комиссия проектларын хәзерләүдә катнашалар;
2) Комиссия компетенциясенә караган барлык мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;
3) конкурс Комиссиясе рәисе йомышларын башкаралар;
4) тиешле белешмә-мәгълүмат материаллары белән танышалар.

4.7. Утырышта конкурс Комиссиясе әгъзаларының 2/3 өлеше катнашса, Комиссия утырышы хокулы булып санала.

4.8. Субсидия бирү турында карар чыгарганда, Комиссия әгъзалары сайлауның түбәндәге критерийларына таянып эш итә:

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Савым сыерларның баш саны:<br>10-12 сыер<br>9 сыер<br>8 сыер<br>7 сыер<br>6 сыер | 1 - 5 балл<br>5 балл<br>4 балл<br>3 балл<br>2 балл<br>1 балл |
| 2 | Шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып бару өчен кулланыла торган җир участогына хокукларны билгеләүче документ (таныклык) яки Күчемсез | 1 - 5 балл |

| | | |
|---|---|---|
| | милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә булуы; | |
| 3 | Импортны алыштыру | 1 - 5 балл |

Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурска бирелгән гаризаларны һәр критерий буенча таләпләр белән 5 баллы шкала буенча бәялиләр (1дә 5кә кадәр).

Конкурс комиссиясе субсидия бирү турында уңай карарны кимендә 7 баллга бәяләнгән һәм иң күп балл җыйган конкурс гаризалары буенча кабул итә. Уңай хәл ителергә тиеш булган конкурс гаризалары санын конкурс Комиссиясе агымдагы елда Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яки) федераль бюджет хисабына чараларны тормышка ашыру өчен бүлеп бирелгән бюджет ассигнованиеләре лимитыннан чыгып бәяли.

4.9. Конкурс гаризаларын тикшерү нәтиҗәләлре буенча конкурс комиссиясе түбәндәге карарлар кабул итә:

субсидия биреләчәк гражданнарны билгеләү турында;

субсидия турында гаризасы кире кагылган гражданнарны билгеләү турында.

4.10. Конкурс комиссиясе карарлары конкурс комиссиясе секретаре алып барган протокол белән тутырыла. Протокол конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан конкурс комиссиясенең утырыш үткәрелгән көнне раслана.

4.11. Протоколда конкурс комиссиясе утырышын үткәрү көне, вакыты һәм урыны, утырышта катнашучы комиссия әгъзалары, тикшерелгән гаризалар саны, конкурс гаризаларын карауның субсидия суммасы һәм эшмәкәрлек объекты теркәлгән муниципаль берәмлек күрсәтелгән конкурс нәтиҗәләре, бирелә торган субсидияләрнең уртак суммасы, субсидия бирү турындагы үтенечләре кире кагылган гаризалар буенча уртак сумма турында мәгълүмат күрсәтелә.

4.12. Протокол расланган көннән башлап, 3 эш көне дәвамында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

4.13. Конкурс гаризасын тикшергәннән соң, субсидия турында үтенече кире кагылган гариза бирүченең тиешле тәртиптә яңа конкурс гаризасын тапшырырга хокукы бар.

Конкурс комиссиясе карары белән субсидия бирелмәгән гариза бирүчегә гаризалар кире кайтарып бирелми һәм билгеләнгән тәртиптә Вәкаләтле оешмада саклана.

4.14. Комиссия әгъзалары аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнашалар.

Кушымта №1

ТР Спас муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык тотучы,
алты һәм аннан күбрәк баш савым сыер асраучы гражданнарга
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджетыннан
саву аппараты сатып алуга киткән чыгымнарның
бер өлешен каплауга субсидия бирү тәртибенә

Руководителю
Исполнительного комитета
Спасского муниципального района РТ

от________________________________
__________________________________
__________________________________
(Ф.И.О., адрес проживания)

Заявление о предоставления субсидий на возмещение
части затрат за приобретенные доильные аппараты личным подсобным хозяйствам, имеющим
шесть и более дойных коров в Спасском муниципальном районе РТ

Я, _______________________________________________________________________,
(Фамилия, имя, отчество)

Паспорт серия ______________, №_________________, выдан_________________________
______________________________________________________________________________
___________________________________________________________________,
проживающий(ая) по адресу:____________________________________________________
_________________________________________________________________________,
телефон ______________________, ИНН _______________________________,
прошу Вас выделить мне причитающуюся субсидию на возмещение части затрат за приобретенные доильные аппараты _____ году.. Сообщаю, что количество дойных коров на личном подворье, расположенное по адресу: Республика Татарстан, Спасский район, ______________________________________________________________________________
_____________________________________________ по состоянию на __.__.______г. составляет __________ (_______________________) голов.

С условиями участия в порядке предоставления субсидии ознакомлен(а) и согласен(а).

В случае предоставлении субсидии, обязуюсь: не уменьшать поголовье дойных коров в течение двух лет после получении субсидии, предоставлять отчетность в запрашиваемые сроки и использовать субсидию по целевому назначению.

Вся информация, содержащая в представленных документах или их копиях, является подлинной, и не возражаю против доступа к ней лиц, участвующих в рассмотрении документов на предоставление субсидии.

____________________ /__________________________/ «____» ___________20___г.
**(подпись)** **(Ф.И.О.)**